РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ ПОДГОРНО-БАЙЛАРСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МЕНЗЕЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ТАУАСТЫ БАЙЛАР
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Тауасты Байлар авыл җирлеге Мияш торак пунктында халык җыены нәтиҗәләре турында**

**«27» ноябрь 2021ел** **№ 3**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 №45-ЗРТ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2021 елның 27 ноябрендә узган халык җыены нәтиҗәләре белән йомгаклау беркетмәсе төзелде, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Тауасты Байлар авыл җирлеге Мияш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2022 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме?, 1-2 төркем инвалидлары, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләр ветераннары, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларның тол хатыннары, көндезге формада белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш, алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

- Мияш торак пунктында су башнясы территориясен тозеклендеру (скважина коймаларын урнаштыру өчен материаллар сатып алу, килешү буенча эшләрне түләү).

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә кертелде 33 халык җыенында катнашучылар саны, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 22 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде 22 халык җыенында катнашучыларны; «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирде 0 җыенда катнашучылар.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Минзәлә муниципаль районы Тауасты Байлар авыл җирлеге Мияш торак пунктында халык җыены булып узды, халык җыены нәтиҗәләре гамәлдә, дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Тауасты Байлар авыл җирлеге Мияш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2022 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертергә, 1-2 төркем инвалидлары, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләр ветераннары, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларның тол хатыннары, көндезге формада белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш, алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

- Мияш торак пунктында су башнясы территориясен тозеклендеру (скважина коймаларын урнаштыру өчен материаллар сатып алу, килешү буенча эшләрне түләү).

3. Тауасты Байлар авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халык җыены нәтиҗәләрен Минзәлә муниципаль районының рәсми сайтында (http:// menzelinsk.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http:/ / pravo. tatarstan. ru) кабул ителгән көннән 10 көн эчендә

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Тауасты Байлар авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Минзәлә муниципаль районы
Тауасты Байлар авыл җирлеге башлыгы: ________ З.С. Гәрәева
(имза) (имзаны киңәйтү)

ОГРН 1021605552792
р 06-115/09
Совет
Поташно-Байларского
сельского поселения
ИНН 1628002996